| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2024 Бима авылы № 18

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мандык авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Бима авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Мандык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын 2024 елның 30 ноябрь көнне 11 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Бима авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Мандык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?":

1. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, койма кору, (зират коймасы өчен материаллар сатып алу).

2. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

3. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (лампаларны, фонарьларны сатып алу һәм алмаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар).

4. Су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу, торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар)

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү (үләннәрне һәм чүп үләннәрен чаптыру өчен тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урамнарны кардан чистарту (запас частьләр сатып алу һәм дизель ягулыгы сатып алу), трактор өчен өстәмә җайланмалар сатып алу, трактор килешүе буенча түләү, балалар уен мәйданчыгы өчен материаллар сатып алу һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Мандык авылы, Ленин урамы, Киров урамындагы 20 нче йорт янында.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.И. Михайлов